**Шәһәр күләмендә математика фәненнән үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы сораулары 2017-18 уку елы**

**10 нчы сыйныф**

**Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.**

**1**. Функция графигының эскизын төзегез: $y(x)=\dfrac{|3x^2+2x-5|}{x-1}$.

**2**. $(a+1)x^2+2ax+a+3=0$ тигезләмәсенең барлык тамырлары уңай булырлык барлык *a* параметрларын табыгыз.

**3**. Ике кисешүче әйләнәнең уртак хордасы берсе өчен камалган төзек дүртпочмак ягы, икенчесе өчен камалган төзек алтыпочмак ягы булып тора. Кечерәк әйләнәнең радиусы 10 см булса, әйләнәләр үзәкләре арасындагы ераклыкны табыгыз.

**4**. Хуҗа Насретдин ипи һәм чәйгә бер акча түләгән. Бәяләр 20% ка арткач, ул шул ук акчага ярты ипи һәм чәй ала алган. Бәяләр тагын 20% ка артса аның акчасы чәйгә булса да җитәрме?

**5**. Диагональләре саны яклар санына караганда 10 тапкыр артыграк булган кабарынкы күппочмак бармы?